МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**13.10.2025** г. Казань **№ 2347**

Махсус хәрби операциядә катнашкан ветераннарының аерым категорияләренә теш протезлары ясау буенча хезмәтләр күрсәтү турында

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына теш протезлары ясау буенча хезмәтләр күрсәтү максатларында, Россия Федерациясе Президентының 2023 елның 3 апрелендәге 232 номерлы Указының 2 пунктындагы «в» пунктчасының икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итүнең дәүләт фондын булдыру» турында, б о е р а м:

1. Кушымтаны расларга:

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләренә теш протезлары ясау буенча хезмәтләр күрсәтү тәртибе;

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләренә теш протезлары ясау буенча хезмәтләр күрсәтүче дәүләт медицина оешмалары исемлеге.

2. Әлеге боерык имзаланган көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр А.Р.Абашев

13.10.2025 елның
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау Министрлыгы
№ 2347 боерыгы белән
расланган

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләренә теш протезлары ясау буенча хезмәтләр күрсәтү

тәртибе

1.Әлеге тәртип «Ватанны саклаучы "махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондын төзү турында» Россия Федерациясе Президентының 2023 елның 3 апрелендәге 232 номерлы Указының 2 пунктындагы «в» пунктчасының икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән хәрби хәрәкәтләр ветераннарына теш протезлары ясау буенча хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

теш протезларын ясау-Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләренә теш протезларын (кыйммәтле металллардан һәм металл керамикадан теш протезлары әзерләүдән тыш) түләүсез әзерләү, урнаштыру һәм төзәтү;

медицина оешмасы – әлеге Тәртипне гамәлгә ашыру кысаларында теш протезлауны гамәлгә ашыручы, тиешле медицина эшчәнлегенә лицензиясе булган, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау Министрлыгы тарафыннан расланган Медицина оешмалары исемлегенә кертелгән медицина оешмасы (алга таба-медицина оешмалары).

3. Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының тешләрен протезлау (алга таба – сугыш хәрәкәтләер ветераннары) түбәндәге аерым категорияләренә медицина күрсәтмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла:

2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә, 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашкан, хәрби хезмәттән (хезмәттән, эштән) азат ителгән хәрби хәрәкәтләр ветераннарына;

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гавами хакимияте органнары карарлары нигезендә Донецк Халык Республикасы Хәрби Көчләре, Луганск Халык Республикасы халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби оешмаларында һәм органнары составында 2014 елның 11 маеннан башлап хәрби хәрәкәтләрдә

катнашкан затларга.

4. Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләренә күрсәтелә торган теш протезлары ясау буенча хезмәтләр исемлеге әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында китерелгән.

5. Хәрби хәрәкәтләр ветераннары медицина оешмаларына мөрәҗәгать иткәндә теш протезлары ясау буенча хезмәтләр алу өчен шәхесне таныклаучы документ һәм хәрби хәрәкәтләр ветераны таныклыгын күрсәтергә тиеш.

Гражданинның хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләренә каравы социаль координатор – «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итүче дәүләт фонды белгече тарафыннан раслана.

6. Әлеге Тәртипне гамәлгә ашыру кысаларында теш протезларын ясау алдыннан граждан медицина оешмасында 2011 елның 21 ноябрендәге «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 323-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы таләпләре нигезендә медицина тыкшынуына мәгълүматлы ирекле ризалык рәсмиләштерелә.

7. Медицина оешмалары әлеге Тәртипне гамәлгә ашыру кысаларында:

хәрби хәрәкәтләр ветераннарын теш протезлары буенча хезмәтләр күрсәтү өчен чиратсыз кабул итү;

хәрби хәрәкәтләр ветераннарына теш протезлары ясау датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирү;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә «хәрби хәрәкәтләр ветераннарына теш протезлары кую буенча күрсәтелгән хезмәтләр турында Акт» персоналаштырылган исәп-хисап рәвешен алып бару;

хисаптан соң килә торган айның 10 числосына кадәр, декабрь өчен – 15 декабрьдән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының икътисадый анализ һәм фаразлау Идарәсенә әлеге Тәртипкә 3-нче кушымтасында каралган форма буенча хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләренә теш протезлары ясау буенча күрсәтелгән хезмәтләр турында хисап (алга таба – күрсәтелгән хезмәтләр турында хисап) тапшыру;

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына теш протезлары ясау буенча күрсәтелгән хезмәтләр өчен кергән акчаларны максатлы файдалану.

8. Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау Министрлыгы хәрби хәрәкәтләр ветераннарына теш протезлары ясау буенча хезмәтләр күрсәтүенең оештыруын тикшереп тора.

9. Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына теш протезларын кую буенча хезмәтләр күрсәтү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 781 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә финанс

белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан гыйбарәт булган башка максатларга субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Медицина оешмаларын финанслау күрсәтелгән хезмәтләр турындагы хисап нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына теш протезларын ясау Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән күрсәтелгән медицина ярдәме өчен тарифларны һәм түләү тәртибен билгеләү турында тариф килешүе белән расланган, теш протезлары ясау буенча хезмәтләр күрсәтүгә мәҗбүри медицина иминияте системасы тарифлары буенча күрсәтелә.

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының
аерым категорияләренә теш протезлары
ясау буенча хезмәтләр күрсәтү тәртибенә
1 нче кушымта

хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләренә
теш протезлары ясау буенча хезмәтләр
Исемлеге

| № п/п | Хезмәт күрсәтү исемлеге |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | Пластмасс материалыннан булган пластинкалы протезлар белән протезлау |
| 1.1. | 1 теш белән |
| 1.2. | 2 теш белән |
| 1.3. | 3 теш белән |
| 1.4. | 4 теш белән |
| 1.5. | 5 теш белән |
| 1.6. | 6 теш белән |
| 1.7. | 7 теш белән |
| 1.8. | 8 теш белән |
| 1.9. | 9 теш белән |
| 1.10. | 10 теш белән |
| 1.11. | 11теш белән |
| 1.12. | 12 теш белән |
| 1.13. | 13 теш белән |
| 1.14. | 14 теш белән |
| 1.15. | анатомия артикуляторында куелган,14 теш белән |
| 1.16. | Хромокобальт эретмәсеннән коелган базис пластинка белән протезлау |
| 1.17. | Корычтан коелган япма белән протезлау |
| 1.18. | Корычтан штампланган япма белән протезлау |
| 1.19. | Корычтан штампланган теш белән протезлау |
| 1.20. | Корычтан бөгелгән кламмер белән протезлау |
| 1.21. | Корыч арматура базисына куеп протезлау (протезны арматуралау) |

| | |
|---|---|
| 1.22. | Тешләрне күчереп куеп, тешләү үзгәрешен алмаштырып протезлау |
| 1.23. | Тешләрне күчереп куеп, тешләү үзгәрешен алыштырмыйча протезлау |
| 1.24. | Төсе яки зурлыгы буенча тешләрне алыштырып протезлау |
| 1.25. | Пластмасс каппа белән протезлау (каппаның 1 звеносы) |
| 1.26. | Протез базисына эластик эчлек белән протезлау |
| 1.27. | Индивидуаль кашык белән протезлау |
| 2. | Алмаш пластинкалы протезларны төзәтү |
| 2.1. | Базис сынуы |
| 2.2. | Ике базис сынуы |
| 2.3. | 1 тешне эретеп ябыштыру |
| 2.4. | 2 тешне эретеп ябыштыру |
| 2.5. | 3 тешне эретеп ябыштыру |
| 2.6. | 4 тешне эретеп ябыштыру |
| 2.7. | 1 кламмерны эретеп ябыштыру |
| 2.8. | 2 кламмерны эретеп ябыштыру |
| 2.9. | 1 тешне һәм 1кламмерны эретеп ябыштыру |
| 2.10. | 1 тешне эретеп ябыштыру һәм базис сынуын төзәтү |
| 2.11. | 2 тешне эретеп ябыштыру һәм базис сынуын төзәтү |
| 3. | Алынмый торган, эретеп ябыштырылган протезлар белән протезлау |
| 3.1. | Корыч пресс коронкасы белән протезлау |
| 3.2. | Корыч штампланган коронка белән протезлау |
| 3.3. | Корыч пресс бюгельле коронка белән протезлау |
| 3.4. | Корыч штампланган бюгельле коронка белән протезлау |
| 3.5. | Коронка спайкасы белән протезлау |
| 3.6. | Пластмасса белән тышланган корыч коронка белән протезлау |
| 3.7. | Индивидуаль коюдан ясалган, коелган корыч теш белән протезлау |
| 3.8. | Стандарт коюдан коелган корыч теш белән протезлау |
| 3.9. | Пластмасс фасеткалы шәхси коюдан коелган корыч теш белән протезлау |
| 3.10. | Пластмасс фасеткалы стандарт коюдан коелган корыч теш белән протезлау |
| 3.11. | Аякчык белән протезлау, күперсыман протезда эретеп ябыштыру |
| 4. | Штифт тешләре, кыстыргычлар, катлаулы коронкалар кулланып протезлау |
| 4.1. | Штифтлы пластмасс теш белән протезлау |
| 4.2. | Коелган корыч белән штифтлы  протезлау |
| 4.3. | Пластмасс фасеткалы коелган корыч штифт белән тешне протезлау |

| | |
|---|---|
| 4.4. | Ричмонд методы буенча коелган корыч штифт белән тешне протезлау |
| 4.5. | Балавыз моделе буенча пластмасс вкладка белән протезлау |
| 4.6. | Амальгам модельләре буенча пластмасс вкладкасы белән протезлау |
| 4.7. | Пластмасс тышчалы һәм штифтлы корыч коронка белән протезлау |
| 4.8. | Тутыгымый торган корычтан ярым коронка белән протезлау |
| 5. | Пластмассадан булган, алынмый торган протезлар белән протезлау |
| 5.1. | Пластмасс коронка белән протезлау |
| 5.2. | Пластмасс күперсыман протезда пластмасс теш белән протезлау |
| 5.3. | Вакытлы пластмасс коронка белән протезлау |
| 6. | Тоташ коелган ,алынмый торган протезлар белән протезлау |
| 6.1. | Хромокобальт эретмәсеннән коелган коронка белән протезлау |
| 6.2. | Пластмасса белән тышланган хромокобальт эретмәсеннән коелган коронка белән протезлау |
| 6.3. | Хромокобальт эретмәсеннән коелган теш белән протезлау |
| 6.4. | Пластмасс фасеткалы хромокобальт эретмәсеннән коелган теш белән протезлау |
| 6.5. | Хромокобальт эретмәсеннән коелган ярымкоронка белән протезлау |
| 6.6. | Хромокобальт эретмәсеннән коелган вкладка белән протезлау |
| 7. | Гипс модельләрендә модельләштерелә торган бюгель протезлар белән протезлау |
| 7.1. | Өске дугалы (каркаслы)протезлау |
| 7.2. | Аскы дугалы (каркаслы)протезлау |
| 7.3. | Коелган базис белән протезлау (дуга урынына) |
| 7.4. | Коелган тешле протезлау |
| 7.5. | Пластмасс фасеткалы коелган теш белән протезлау |
| 7.6. | Терәкле кламмер белән протезлау |
| 7.7. | Бер җилкәле кламмер белән протезлау |
| 7.8. | Т-сыман кламмер белән протезлау |
| 7.9. | Күп буынлы кламмер белән протезлау (бер буын) |
| 7.10. | Терәк (өстәмә)табан белән протезлау |
| 7.11. | Тармаклы протезлау |
| 7.12. | Базисны беркетү өчен ияр (челтәр) белән протезлау |
| 7.13. | Базисны чикләүче белән протезлау |
| 8. | Утка чыдам модельләрдә модельләштерелә торган бюгель протезлар белән протезлау |
| 8.1. | Өске алгы дугалы (каркаслы) протезлау |
| 8.2. | Өске арткы дугалы (каркаслы) протезлау |
| 8.3. | Өске арткы һәм алгы дугалы (каркаслы) протезлау |
| 8.4. | Аскы дугалы (каркаслы) протезлау |
| 8.5. | Коелган базис белән протезлау (дуга урынына) |

| | |
|---|---|
| 8.6. | Аңкау  пластинкасы белән протезлау |
| 8.7. | Телле пластинка белән протезлау |
| 8.8. | Коелган тешле протезлау |
| 8.9. | Пластмасс фасеткалы протезлау |
| 8.10. | Терәкле кламмер белән протезлау |
| 8.11. | Бер җилкәле кламмер белән протезлау |
| 8.12. | Боҗралы кламмер белән протезлау |
| 8.13. | Икеле кламмер белән протезлау |
| 8.14. | Т-сыман кламмер белән протезлау |
| 8.15. | Күп буынлы кламмер белән протезлау (бер буын) |
| 8.16. | Шинирлаучы (эләктереп алучы)табан белән протезлау |
| 8.17. | Тармаклы протезлау |
| 8.18. | Базисны беркетү өчен ияр (челтәр) белән протезлау |
| 8.19. | Базисны чикләүче белән протезлау |
| 8.20. | Окклюзион накладка белән протезлау |
| 8.21. | "Откап"тибындагы йозак системасы белән протезлау |
| 9. | Эшләрнең башка төрләре |
| 9.1. | Штампланган иске коронканы алу |
| 9.2. | Коронканы  цементлау |
| 9.3. | Альгинатаның күчермәле массасыннан оттискны булдыру |
| 9.4. | Тоташ коелган иске коронканы алу |
| 9.5. | Силиконның күчермәле массасыннан оттискны булдыру |
| 9.6. | Корронканы  вакытлыча теркәү |
| 9.7. | Коронканы пыяла-номер цементка даими беркетү |
| 9.8. | Препарациялләгәннән соң тешләрне эшкәртү (фторлак белән) |
| 9.9. | Регистратор ярдәмендә тешләүне билгеләү |
| 9.10. | Стоматолог-ортопедның тикшерүе |
| 9.11. | Оропантомограмма |
| 9.12. | Рентген сурәте |
| 9.13. | Аппликацион Анестезия |
| 9.14. | Инфильтрацион яки үткәргеч Анестезия |

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының
аерым категорияләренә теш протезлау
буенча хезмәтләр күрсәтү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

хәрби хәрәкәтләр ветераннарына теш протезлары ясау буенча
күрсәтелгән хезмәтләр турында
АКТ № ______

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(медицина оешмасы исеме)

___________________________________________________________________________
(пациент исем-фамилиясе)

___________________________________________________________________________
(ташламалы категория исеме)

| Дата | Хезмәт коды | Хезмәт күрсәтү исеме | Тариф, сум | Микъдар | Сумма, сум |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Нәтиҗә | | | | | |
| | | | | | |

Дәвалаучы врач___________________ Баш табиб______________________
исем-фамилия (имза) исем-фамилия (имза)

Пациентның имзасы һәм дата _______________ ______________________
исем-фамилия (имза) медицина оешмасы мөһер урыны

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының
аерым категорияләренә теш
протезлау буенча хезмәтләр күрсәтү тәртибенә
2 нче кушымта

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләренә теш протезлары ясау буенча
күрсәтелгән хезмәтләр турында
хисап

| Медицина оешмасы исеме | Таашламлы категория исеме | Дата | Хезмәт коды | Хезмәт күрсәтү исеме | Тариф, сум | Микъдар | Сумма, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| Итого: | | | | | | | |

Баш хисапчы ______________________ Баш табиб _______________________
исем-фамилия (имза) исем-фамилия (имза)

_________________________
медицина оешмасы мөһер урыны

13.10.2025 елның
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау Министрлыгы
№ 2347 боерыгы белән
расланган

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләренә теш протезлары ясау буенча хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы дәүләт медицина оешмалары исемлеге

| № п/п | Медицина оешмасы исеме |
|---|---|
| 1 | ДАССУ «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының республика стоматология поликлиникасы» |
| 2 | ДАССУ «Азнакай район үзәк хастаханәсе» |
| 3 | ДАССУ «Алексеевск район үзәк хастаханәсе» |
| 4 | ДАССУ «Әлки муниципаль районының Базарлы Матак район үзәк хастаханәсе» |
| 5 | ДАССУ «Әлмәт стоматология поликлиникасы» |
| 6 | ДАССУ «Апас район үзәк хастаханәсе» |
| 7 | ДАССУ «Арча район үзәк хастаханәсе» |
| 8 | ДАССУ «Әтнә район үзәк хастаханәсе» |
| 9 | ДАССУ «Баулы район үзәк хастаханәсе» |
| 10 | ДАССУ «Балтач район үзәк хастаханәсе» |
| 11 | ДАССУ «Бөгелмә район үзәк хастаханәсе " |
| 12 | ДАССУ «Буа район үзәк хастаханәсе» |
| 13 | ДАССУ «Биектау район үзәк хастаханәсе» |
| 14 | ДАССУ «Чүпрәле район үзәк хастаханәсе» |
| 15 | ДАССУ «Зәй район үзәк хастаханәсе» |
| 16 | ДАССУ «Зеленодольск район үзәк хастаханәсе» |
| 17 | ДАССУ «Кайбыч район үзәк хастаханәсе» |
| 18 | ДАССУ «Кукмара район үзәк хастаханәсе» |
| 19 | ДАССУ «Лаеш район үзәк хастаханәсе» |
| 20 | ДАССУ «Лениногорск район үзәк хастаханәсе» |
| 21 | ДАССУ «Мамадыш район үзәк хастаханәсе» |
| 22 | ДАССУ «Минзәлә район үзәк хастаханәсе» |

| | |
|---|---|
| 23 | ДАССУ «Мөслим район үзәк хастаханәсе» |
| 24 | ДАССУ «Яңа Чишмә район үзәк хастаханәсе» |
| 25 | ДАССУ «Нурлат район үзәк хастаханәсе» |
| 26 | ДАССУ «Питрәч район үзәк хастаханәсе» |
| 27 | ДАССУ «Балык Бистәсе район үзәк хастаханәсе» |
| 28 | ДАССУ «Саба район үзәк хастаханәсе» |
| 29 | ДАССУ «Сарман район үзәк хастаханәсе» |
| 30 | ДАССУ «Спас район үзәк хастаханәсе» - «Республика клиник хастаханәсе» филиалы |
| 31 | ДАССУ «Тәтеш район үзәк хастаханәсе» |
| 32 | ДАССУ «Тукай район үзәк хастаханәсе» |
| 33 | ДАССУ «Теләче район үзәк хастаханәсе» |
| 34 | ДАССУ «Чирмешән район үзәк хастаханәсе» |
| 35 | ДАССУ «Чистай район үзәк хастаханәсе» |
| 36 | ДАССУ «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу район үзәк хастаханәсе» |
| 37 | ДАССУ «1-нче номерлы стоматология поликлиникасы» |
| 38 | ДАССУ «2 нче номерлы стоматология поликлиникасы» |
| 39 | ДАССУ «3 нче номерлы стоматология поликлиникасы» |
| 40 | ДАССУ Казан шәһәре «18 нче шәһәр поликлиникасы» |